Әнәс Хәсәнов

# Узыгыз күңел түремә



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2010

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Х91

**Хәсәнов, Ә.Х.**

Х91 Узыгыз күңел түремә : шигырьләр, җырлар / Әнәс Хәсәнов ; кереш сүз авт. Г.Садә. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 111 б.
ISBN 978-5-298-01955-2

Шагыйрьнең бу китапка кергән шигырьләре, җырлары сөю-ярату, кайгыру-әрнү, шатлану-җилкенү, соклану-гаҗәпләнү, нәфрәтләнү-чиркану нәтиҗәсендә күңел тибрәнүләреннән туган. Аның йөрәгеннән саркып чыккан хисләр, бәлкем, башкалар җанында да кайтаваз табар, яратырга, сокланырга, матурлык алдында баш иярга өндәр. Шулай булса, кеше дөньяви ваклыклардан югары күтәрелер, азмы-күпме аның рухи офыгы киңәер, тормыш-көнкүреше яктырыбрак китәр, яшәешнең гүзәл яклары ачыла төшәр дигән өметтә калабыз.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01955-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Хәсәнов Ә.Х., 2010

# МАТУРЛЫК ТАНТАНАСЫ

Шигърият – шагыйрьләрнең йөрәк җылысы белән өртелгән матурлык бакчасы ул. Анда барысы да тере һәм җанлы, без инде күптән күнегеп беткән, гап-гади нәрсәләр дә яңа бер бизәк, төсмер алып гүзәллек үрнәге булып балкыйлар. Көндәлек тормышның гадәти күренешләрен югарырак күтәреп, кояшка якынайтыбрак сынландырудан, тасвир кылудан башка шигърият була алмый. Шатлык һәм хәсрәт, сөенеч һәм көенеч, тәвәккәллек һәм сабырлык, кыюлык һәм тыйнаклык, әле тагын әллә никадәрле хис-тойгыларны, адәм балаларының холык-фигылен, табигать фасылларын, вакыт агышын – боларның барысының да бер-береннән аерылгысыз икәнлеген, бербөтен булып гармония тәшкил итүен чагылдыра ул шигърият. Анда мәхәббәт тантана итә. Шагыйрьнең йөрәк тибешен, гомер агышын, күңел дөньясын шул билгели.

Гомер тавының биек үренә күтәрелгән ихлас җанлы татар шагыйре Әнәс ага Хәсәнов тикмәгә генә үзенең бу шигъри җыентыгына «Узыгыз күңел түремә» дип исем кушмагандыр. Китапны кулга алып, андагы берничә шигырьне укуга ук, шагыйрьнең олпат затларга гына хас тирән фәлсәфи фикер йөртүен, күңеленең киңлеген, иркенлеген тоясың. Бу тормышта берни дә үзеннән-үзе генә килми. Хакыйкать тә, тәҗрибә дә яшәлгән гомер бәрабәренә туплана. Әлбәттә, мәгънәле итеп, яратып яшәгән гомер хисабына. Мәхәббәт яшәтә, яшәртә, шул ярату ялкыны йөрәккә дәрт өсти. Шуңа да еллар биеклегеннән торып, берәүне дә кабатламыйча, бераз гына сискәндереп, шагыйрьнең бик тә кыска, әмма үтемле итеп:

Ыргы кирәкми йөрәккә,
Мәхәббәт җыры кирәк.
Мәхәббәтсез йөрәкләр бар,
Шөкер, андыйлар сирәк, –

дип әйтүе күпләр күңеленә хуш килә. Бу җәһәттән «Кояшка алмашка» дигән шигырендә ул мәхәббәтне гап-гади җир кешесе буларак яңа яктан ача. Автор, яшь чагында юлын чу-

алтып, үз кояшын югалткан кешене сурәтли. Мондый хәл – кем өчен дә олы кайгы, әлбәттә. Әмма аны бәхет тә читләп узмый, юлында ул үз тиңен очрата. Баш очында куерган болытлар тарала. Һәр көне киеренке хезмәт белән узган гомерендә зур кичерешләр кичергән каләм әһеле:

Син килдең күгемә
Кояшка алмашка...
Тормышка мәхәббәт
Кабыздың күңелдә.
Сүрелмәс дәрт белән
Яшим мин бүген дә, –

дип, мәхәббәтнең гади, әмма әнә шундый мәрхәмәтле, кодрәтле көчкә ия булуын тасвирлый.

Гомумән, җыентыкта мәхәббәт темасы шигырьдән шигырьгә күчеп укучыны озатып бара. Һәр эш-гамәлебезне бисмилла әйтеп башкарган кебек, без дә мәхәббәтнең мәңгелегенә мәдхия җырлаган «Казаным» шигыре белән китапның беренче битен ачабыз. Шанлы-шөһрәтле, меңьеллык тарихы булган башкалабыз картаймый, шагыйрь өчен ул һаман яшәрә генә бара, янып, яратып һәм илһамланып иҗат итү учагы булып кала:

Менә Болак, аның сөзәк яры
Нәкъ шушында,
Каян килде мондый кыюлык?!
Күкрәгемә кысып гүзәлемне
Үптем, мең ел йөргәч җыенып.

Тормыш юлында адашмыйча бару өчен Тукай һәм Туфаннардан канат алган шагыйрь үз укучысы белән бергә «күңел кылын Сәйдәш моңына көйли-көйли, мәйданнардан уза» һәм яшәешнең асыл мәгънәсен, аның ачкычын таба. Бу уңайдан «Табигатьтә камиллек» шигырен мисал итеп китерәсе килә:

Көенәсең –
нишләде бу һава,
һаман яңгыр ява,
аннан тагын –
әйтерсең лә янгын,
көннәр эссе, эссе гел.
Табигатьтә һава көйсез булмый,
без үзебез көйсез, шуны бел.

Әнә шундый, туган телебезнең кодрәтен һәм нечкәлеген тоеп, шагыйрь үзенең изге хыял-максатын – дөньяны яхшырту теләген укучыга җиткерә. Моны аның «Ватаным дип сөеп әйтү өчен», «Вакыт», «Язмыш», «Юл чатында», «Төш» кебек шигырьләре ачык раслый.

Авторның классик шәрык шагыйрьләре кебек киң һәм тирән фәлсәфи фикер йөртүе иҗатының офыгын тагын да киңәйтә. Мәсәлән, аның «Күләм» һәм «Фәлсәфә» дип аталган дүртьюллык шигырьләрендәге фәлсәфәне фикер белән тойгы-хис берлегенең югары баскычы ул дип әйтергә мөмкин:

Җиһанның һәр инсаны –
Ком бөртеге нибары.
Әхлакый нур калдырса,
Һәр кеше ул – Җир шары.

Безнең халыкта «кыскалыкта – осталык» дигән гыйбарә киң таралган. Моңа Ә.Хәсәновның «Борынгылар сүзе» шигыре ачык мисал була ала:

Борынгылар белеп әйткән –
Балык башыннан чери.
Көтүчесез сарыкларны
Кәҗәләр ияртеп йөри.

Шагыйрьнең күңел офыгы киң, иҗаты күпкырлы, күптармаклы. Ул һәммәбез өчен дә изге булган халкыбыз һәм туган телебез язмышы өчен борчыла, ут йота, әрни, көенә, уйлана. «Ник шулай Рәсәйдә?», «Татарга бил нәрсәгә», «Татарым», «Ник түзәбез?», «Без кем?» кебек шигырьләре әнә шундый җан әрнеше белән язылган.

Без битараф, салкын канлы булгач,
Телебезне хәтта кисәләр.
Түзәрбезме, мифик дәүләт теле,
Татар теле юк ул, дисәләр, –

дип шагыйрь чаң суга «Ник түзәбез?» дигән шигырендә. «Карт имән» шигыре исә безгә тарихтан бер гыйбрәтле сабак буларак яңгырый:

Кешеләр нәрсә бүлделәр
Чулман ярында.

Кылычка-кылыч килделәр
Имән янында...
Йөзьяшәр имән тирәсе –
Тоташ каберлек.
Гасырлар буе түзәргә
Кирәк сабырлык.

Шагыйрь Әнәс Хәсәновның бу җыентыгын укучы яратыр, үз итәр. Ул аның юмор һәм сатира белән өртелгән шигырьләрен укыгач рәхәтләнеп елмаер. Автор, Тукай алымын оста кулланып, «Шүрәленең Казанда күргәннәре» исемле сатирик шигырендә бүгенге чорыбызның ямьсез күренешен, тискәре ягын, иман юлыннан качкан кайбер яшьләребезнең әхлаксызлыгын, оятсызлыгын фаш итә. «Тәкъва эшмәкәргә», «Килде-килде халыкка «влач»», «Офык», «Кодалардан бик уңдым», «Маркет ачтым» дигән шигырьләре шагыйрьнең юмор жанрында каләме үткен һәм көчле икәнен күрсәтәләр.

Китапның үзенә тартып торган тагын бер бизәге – автор анда композиторлар тарафыннан көй күлмәге кидерелгән, җыр теленә күчкән шигырьләрен туплаган. Җыр шигырьгә икенче яшәеш алып килә. Алар шагыйрьнең бүген дә картлыкны онытып, яшьләрчә җырдан рух алып яшәве турында сөйлиләр.

Кадерле укучым! Менә синең кулыңда шагыйрь Әнәс Хәсәновның Татарстан китап нәшриятында зәвык белән матур итеп чыгарылган «Узыгыз күңел түремә» дип исемләнгән шигырьләр җыентыгы. Әйдәгез, без шагыйрь чакырган түргә узыйк. Анда безне мәхәббәт сулышы белән өртелгән, матурлык тантанасы дип аталган шигърият дөньясы каршылый.

*Госман Садә*

# Мин тормышка гашыйк



## КАЗАНЫМ

Мин яратам гүзәл Казанымны,
Бик яратам иске урамын.
Яңасы да якын, –
Ул иртәгә иске...
Менә әле тагын урадым
Яңа-иске Казан урамнарын,
Эзләп түгел аннан берәрсен.
...Хәер, ялгышам ла бугай,
Эзләдем лә... Әй, укучым,
Әйтсәм, бәлкем, миннән көләрсең,
Көләрсең шул,
Әгәр белә калсаң
Чәчем агарганын күптәннән,
Ә шулай да
Көләч, алсу йөзле
Күңел кошын
Уйларымда һаман йөрткәннән.
(Әйтсәм әйтим инде...
Һәм тагын бер...
Хыялымда суырып үпкәннән.)

Менә Болак, аның сөзәк яры,
Нәкъ шушында
Каян килде мондый кыюлык?!
Күкрәгемә кысып гүзәлемне
Үптем, мең ел йөргәч җыенып.
Әйе, әйе,
Казан урамнары,
Иске йортлар шаһит иделәр,
Алар күрде кайнар иреннәрне
Мин үпкәнне,
Белмим, мактап,
Белмим, көнләшепме,
Менә егет икән, диделәр.

Казан урамнарын
Урап йөрим,

Рәхмәт сиңа,
Нурлы Казаным,
Яшьлегемне мәхәббәтле иттең,
Сөенечле, көләч, гөл-чәчәкле,
Милли горур – килер-киләчәкне,
Шуңа күрә рухи таза мин,
Мәңге яшә, нурлы Казаным!

Казан! Казан!
Бөек, мәгъруур кала,
Ата-бабаларым бишеге,
Кеше булсыннар дип безгә ачтың
Белем йортларының ишеген.

Ташып торган өмет,
Хыял белән
Килеп кердек урамнарыңа,
Яшьлек белән төкереп тә бирми
Яңгырларга, бураннарына.

Белем эстәп малайлыктан чыктык,
Егет булып
Чумдык хезмәткә,
Чыныктык без синдә,
Данлы Казан,
Син өйрәттең безне
Гаделлеккә,
Гаделсезлек күрсәк, түзмәскә.

Ирләр булып тормыш йөген тарттык,
Сукранмадык ай-һай авыр дип.
Дөнья кудык, ә ул безне куды,
Чын ирләр ул түзем, сабыр дип.

Казан! Казан!
Чал тарихың –
Әхлак әлифбасы,
Ә бүгенгең –
Дуслык көзгесе.
Гакыл белән, зур ышаныч белән
Киләчәкне төзү өлгесе.

Синең урамнарың,
Иске йортлар
Хәтерлиләр булыр безне дә,
Таң атканчы кайнар кочаклардан
Аерылалмый үткән сәгатьләрне,
Сөям дигән изге сүзне дә,
Бөтен дөнья, бөтен җиһан сыйган
Дәрья кебек төпсез күзне дә.
(Хәзер инде сагыш-сагынудан
Йөрәгеңне учлап түз генә.)

Һәй, бу кешең!
Нинди гаҗәеп зат,
Аяк басса туган җиренә,
Тәүге мәхәббәте кичекмәстән
Калка шундук хәтер түренә.

Саф мәхәббәт әллә мең яшәргә
Җир-анадан азык аламы?
Йөрәкләргә Ходай сөю дәртен
Туган җирдә юмарт саламы?

Мәйданнардан узам,
Күңел кылын
Көйли-көйли Сәйдәш моңына.
Һәм сөенәм шуңа – канат бирә
Тукай, Туфан тормыш юлыма.

Урамнардан йөрәгемә үрли
Ялкын сыман Такташ хисләре,
Менә шулай җанны җанга бәйли
Казанымның сихри кичләре.

Данлы Казан!
Мин бит сиңа гашыйк,
Бөтен рухым белән яратам.
Урамнарың көмеш ташларыннан
Тарих аңкый,

Ә күгеңдә яшьлек дәрте балкый,
Илһам чыганагым – башкалам.

Казан! Казан!
Сөекле башкалам,
Мәңгелек яшь, гүзәл ак таш калам!
Абруеңа синең ярасам,
Улың ит син мине, изге шәһәр,
Якын күрсәң, тиң дип санасаң,
Улың ит сине мине, ярасам,
Улың ит!

## БЕЗНЕҢ БӘХЕТ

Сандугач эчкән көмеш чык
йөзебезне чылаткан.
Безнең бәхет шуннан килә –
без бит авылдан чыккан.

Шәфталу, бананнар түгел,
бәрәңге ашап үскән.
Ата-бабалар юлыннан
тормышка чыгып киткән.

Тальян гармун дәртле моңы
илһам биргән, куаныч,
Ватанпәрвәрлек дигәндә
илдә безгә ышаныч.

Намусыбыз пакь булсын дип,
олылар бик тырышкан,
Бәхетебез шуннан килә –
без хезмәттә чыныккан.

## ҮТЕНЕЧ

Авырып китсәм әгәр, әйтеп куйыйм:
Кендек каным тамган якларның
Шифа булыр миңа зәмзәм кебек,
Туган җирнең суы, Актайның.

Туган ягым суы – сихәтле су,
Тәнем савыктырыр – белегез.
Сөеп биргән сые бер Ходайның
Сихри дәва җанга – телебез.

Милләттәшләр, рухым арый калса,
Савыксын дип шагыйрь улыгыз,
Дога итеп миңа Такташ, Муса,
Тукай шигырьләрен укыгыз.

## БУЛСА БУЛСЫН

Гафу итсен мине йолдызларым,
балкышлары миңа кирәкми, –
гомер узса телгәләми генә
татлы газап – сөю йөрәкне.

Тәкъдир итсә әгәр мәхәббәтнең
чиле-пешле, шашкын түгелен, –
чәчәк-гөлләр миңа елмаймасын,
китек калса калсын күңелем.

Миңа булсын дәрья кебек чиксез,
кояш сыман кайнар, нурлы хис.
Тормышымны бизәп, бәйрәм итеп,
ташкын булып килсен тугры хис.

## АВЫЛЫМА МӘДХИЯ

Йөрәкнең нинди түрендә
Мәңге саклана икән
Яшел чирәмле авылым
Һәм елгам Актай дигән?

Ул юа тулы болыннар,
Гөл-чәчәкле урманнар,
Ул җиләк тулы аланнар,
Хуш ис аңкып торганнар!

Ул тәрәзә каршысында
Ефәк шәлле шомыртлар!
Ул фәрештә канатыдай
Күктәге ак болытлар!

Ул авылның тынга чумган
Ажаганлы кичләре,
Дулкын-дулкын иген кыры,
Язгы яңгыр исләре!

Яшел чирәмле авылым
Һәм елгам Актай дигән!
Сездән бит ул җаныма рух,
Тәнгә куәт, көч ингән.

## МИН БЫЛБЫЛ БУЛСАМ ИДЕ

Мин былбыл булсам иде.
Тәрәзәңә оя корып,
Иртән-кичен гөлгә кунып,
Гел сайрап торсам иде.

Мин кояш булсам иде.
Нурларымнан сарай салып,
Миннән дәрт һәм илһам алып,
Син шунда торсаң иде.

Мин чәчәк булсам иде.
Күкрәгеңә ятып, балкып,
Ал иренеңнең балын татып,
Иркәләп торсам иде.

* * *

Тәрәзә чиертә егет,
Йолдызы шат, елмая,
Мәхәббәтле тәрәзәләр
Нур чәчәләр дөньяга.

* * *

Якын килсәң, ялкын өтә, пешерә,
Йөрәгендә сөю туса, кеше дә
Йә көйдерә, йә көя ул үзе дә,
Мәхәббәт ул – татлы газап, түз генә.

## МӘХӘББӘТКӘ ДАРУ

Беләсезме, мәхәббәткә
дару тапканнар икән,
Аны өләшкәндә, күпләр
чыгып качканнар икән!

* * *

Быргы кирәкми йөрәккә,
Мәхәббәт җыры кирәк.
Мәхәббәтсез йөрәкләр бар,
Шөкер, андыйлар сирәк.

## КОЯШКА АЛМАШКА

Болытлар, куерып,
Юлымны чуалтты.
...Яшь идем, ялгыштым,
Кояшны югалттым.

Син килдең күгемә
Кояшка алмашка
Һәм балкып кул суздың,
Ялгызым калмаска.

Тормышка мәхәббәт
Кабыздың күңелдә.
Сүрелмәс дәрт белән
Яшим мин бүген дә.

## МӘҢГЕ КАЛСЫН СӨЮ

Бакчаларга кереп,
Әйдә бер утырып
Тыңлыйк сандугачлар шашканны.
Йөрәкләрне кушып,
Бер гәпләшик әле –
Яшьлек хыяллары
Адашканмы, канат какканмы?

Әйдә телик әле
Шифалы яңгырлар
Күңелләргә коеп яусын дип,
Юып алып китсен
Салкын сагышларны,
Иске ялгышларны,
Сөю генә мәңге калсын дип.

Бездән соңгы яшьләр
Галиҗәнап сөю –
Мәхәббәтнең кадрен белсен дип.
Күктәге йолдызлар,
Йолдыз күзле кызлар
Дөньяга матурлык,
Тормышка ямь, ләззәт бирсен дип.

* * *

Ашкынулы йөрәкләргә
Йөгән түгел, наз кирәк.
Дөньяның йөгәннәре күп,
Ә назлары ник сирәк?

## ҮПКӘЛӘМИМ

Үпкәләмим көзгә,
Үпкәләмим,
Яңгырлары белән килсә дә,
Болытлары белән күкне каплап,
Теңкәгезгә тиям дисә дә.
Үпкәләмим көзгә,
Ул барыбер тиздән юл бирәчәк
Нурлы, якты, җылы көннәргә,
Урамнарга гөрләп туй киләчәк
Чәчәкләргә күмеп, гөлләргә.
Әйдә яусын, әйдә койсын яңгыр,
Күңелләрдә безнең яз булгач,
Яңгыр ни ул, кайнар йөрәкләргә
Ишелеп-ишелеп килеп наз тулгач.

## КӨЗ

Сусаль алтын урманнарга кунган,
серле сагыш баскан кырларны,
сагыналардыр шифа яңгырларны,
тургай сузган язгы җырларны.

Ялан таулар, ялан болыннарны
күреп гаҗәпләнә кояш та,
җил дә бүген нәүмиз, әллә нинди,
үзе усал, үзе юаш та.

Киек казлар һәм торналар моңы
күктән иңә җиргә – көз инде.
Сандугачлы язлар тагын килер,
туган җирем, бераз түз инде.

## ЯЗЫМ ИРТӘ КИЛДЕ

Бакчаларда тюльпан бәйрәм итә,
Купшы таҗын кигән сиреньнәр,
Хуш ис бөркеп миңа елмаялар,
Кай арада үстең син, диләр.

Үскәнсең дип, зәңгәр киңлекләрдән
Алтын кояш сөеп елмая.
Нишләдең соң быел, әй йөрәгем,
Ашкынасың һаман син кая?

Әллә миңа канат чыга микән,
Очып кына йөрим бу язда.
Чәчәкләрнең гүзәл тәэсиреннән
Сусап тора күңел гел назга.

Үзем җирдә әле, ә күңелем
Тыелгысыз күккә омтыла.
Бакчаларда чут-чут кошлар сайрый,
Дәресләрем тагын онытыла.

Чәчәкләрме сәбәп, сандугачмы,
Сусап тора күңел гел назга,
Бар дөньяны кочагыма алып
Очып кына йөрим бу язда.

## КЫЗЛАРЫМА

Әти булу – чиксез бәхет,
Алма кебек кызларның.
Бер елмаюыгыз эретә
Тормышымның бозларын.

Күңелегез якты булса,
Нурлы булыр дөнья да.
Сез бит кояш кыйпылчыгы,
Күктә йолдыз өр-яңа.

Сез бик нәни, белмисез шул
Әтиләр горурлыгын.
Өмет-хыял диңгезендә
Ак җилкән булырлыгын.

Үсегез, үс, дөнья якты,
Сездән ташый яктылык.
Омтылыгыз кешеләргә
Эшләргә гел яхшылык.

Күңелегез нурлы булса,
Нурлы булыр дөнья да,
Сез бит миңа Кояш җирдә,
Күктә йолдыз өр-яңа.

## СӨЮ – БӨЕК ЛӘЗЗӘТ

– «Сөю – бөек ләззәт» дию – сүз генә,
Яндыра ул, көйдерә ул, түз генә.
– Ник соң кеше бик шат көн-төн янарга –
Татлы газап – тансык ширбәт аңарга.

## САНДУГАЧТАН ҖЫР КАЛА

Салкын җил тирәкне тибрәтә,
Сандугач оясы чайкала.
Ояда баласы ник ялгыз?
Егылып төшәр бит бу бала.

Көчле җил ояны кубара...
Сандугач баласын Җир-ана
Куенына ала да юата.
...Дөньяда сагышлы җыр кала.

## МИН ЯЗЛАРГА ЫШАНАМ

Үчләнсә дә кышкы салкын,
Мин языма ышанам.
Күңелдәге бураннардан
Мин яз көне бушанам.

## ГҮЗӘЛ КЫШ

Бүген кояш назга юмарт,
Табигатьтә гүзәл бәйрәм.
Нечкә билле яшь чыршылар
Уйнап йөри әйлән-бәйлән.

Башларында ука калфак,
Иңнәрендә ефәк ап-ак.
Көмеш көртләр колач җәя,
Үбәргә дип бер кочаклап.

Каен кызы иркә, назлы,
Тыйнак, чибәр, бөдрә кашлы,
Якын итә матур кышны,
Ә сагына җылы язны.

## ИГЕНЧЕ

Юкны бушка авыштырган –
Игенче түгел. Түгел!
Бу дөньяда шөгыльләр күп,
Игенче шөгыле – ШӨГЫЛЬ.

Сүздән ботка да пешерми,
Бурамый сүздән бура.
Сабыр гына үз эшендә
Муллыкка нигез кора.

Тыйнак юмартлыгың өчен
Рәхмәт сиңа, игенче!
Елдан-елга насыйп булсын
Игенче сөенече.

* * *

Чәчәкле язга бирешә
Чалмалы кыш билләре.
Гөлләрдән такыя үрә
Җиләкле җәй җилләре.

## ТАБИГАТЬТӘ КАМИЛЛЕК

Көенәсең –
нишләде бу һава,
һаман яңгыр ява,
аннан тагын –
әйтерсең лә янгын,
көннәр эссе, эссе гел.
Табигатьтә һава көйсез булмый,
без үзебез көйсез, шуны бел.

## КОЯШЛЫ МОҢ

Тормыш дигән олы юлда
Миллион юлдашына
Җыры белән канат куя
Фәридә Кудашева.
Фәридә – җырчы фәрештә,
Кояшлы моң җиһанда,
Моңлы иҗат – рухи азык
Һәр җанга, һәр инсанга.

## УКЫТУЧЫМА

*Профессор Лия Закир кызы*
*Шакировага*

Җан чишмәгез тулы сулы,
Укытучым,
Күңелләрдә җан азыгы – рух
Тукучым.

Белем алу – энә белән кое казу,
Белем бирү – саф күңелгә дога язу.

Яшь йөрәкләр түренә сез нур чәчтегез,
Бәхет дигән олы илгә юл ачтыгыз.

Хафаланмыйк вакыт үтә, сиздерми дип,
Вакытның да үлчәве бар – ул хезмәт бит.

Хезмәтегез шәрәфәтле, Идел хәтле,
Чәч көмеш тә, йөрәгегез һаман дәртле.

Исемегезне сөеп, мактап меңнәр атый,
Шөһрәтегез бакый, гүзәл, нурдай балкый.

Олпат галим, мәгърифәтле Закир кызы,
Халкыбызның юмарт җанлы таң йолдызы.

Укытучым бик бәхетле, пар канатлы –
Ихтирам һәм мәхәббәт ул – Лия атлы.

## ЯЗГЫ ТАҢ ХАТИРӘСЕ

Җилнең әле сабый, иркә чагы,
агач башларына уралып,
әйлән-бәйлән уйный торган чагы,
яңа көн туганга куанып.

Кояшның да әле битен юып,
кершән сөртеп йөргән бер чагы,
төнлә генә болытларны куып,
җиргә ачты кайнар кочагын.

Җир назлана, киерелә күккә,
көязләнә, аңа и рәхәт:
җылы яңгыр күкрәгенә иңде,
бәрәкәткә өстәп бәрәкәт.

# Мин дөньяны яхшыртырга телим



## ВАТАНЫМ ДИП СӨЕП ӘЙТҮ ӨЧЕН

Эш-гамәлен өйрән син кешенең,
белим дисәң кемнең кемлеген,
башкаларга мөнәсәбәтен кара,
кая береккәнен кендеге.

Илне дә нәкъ шулай – ул-кызына
нинди тормыш кору бәяли,
Ватаным дип сөеп әйтер өчен
халкына киң кочак җәяме?

Туган илең әгәр синдә күрсә
чын хуҗасын, тугры иясен
һәм сөекле бала итсә генә,
аңа Ватан-анам диясең.

## ГОМЕР ЮЛЫ – СИРАТ КҮПЕРЕ

Гомер юлы, ай-һай, җиңел түгел,
Адым саен рухи сикәлтә.
Яшь болындай йөгереп узу кирәк,
Шуыша калсаң, инде син – кәлтә.

Кәлтә булмыйк, мескен, курка калса,
Өзеп кача бик тиз койрыгын.
Кеше булыйк, сәгать-минут саен
Үтәп яшик намус боерыгын.

Бу дөньяда яшәү җиңел түгел,
Көн дә узам сират күперен.
Шуңа шат мин, кәлтә булып түгел,
Кеше булып үтә гомерем.

## ВАКЫТ

Яшь егетләрне картайта,
Санламый солтаннарны,
Континентларны тетрәтә,
Санамый корбаннарны.

Хәсрәт-дәрьяга кешене
Җәлләми, тотып сала.
Теләсә, йөрәк ярасын
Дәвалап, юып ала.

Хөкем итсә, гүзәл илләр
Айкала да таркала.
Дустан дошманга әйләнә
Башкалага башкала.

Йөзгә җыерчыклар сибә.
Диңгез кибә. Елгалар,
Бормалы юлларын ташлап,
Бер аңа буйсыналар.

Бу нинди илаһи куәт,
Нинди гайрәт һәм дәрман?
...Шундый бөек көч иясе
Бакый Вакыт – каһарман.

## ЯЗМЫШ

Язмыш үги ана сыман,
Кырыс аның холкы,
Тели икән, ятим итә,
Тамырыңны йолкый.

Теләсә, рәхиме килеп
Сине ул үз итә.
Теләмәсә, шәфкать көтмә,
Үзәгеңә үтә.

Кешене кеше итә ул
Йә чырадай телә.
...Тәкъдиренә ни язганын
Кем генә соң белә?

## УФТАНМЫЙК

Ал җилкәннәрем булмады
Диеп һич тә уфтанмыйм.
Канатым юк, оча алмыйм
Диеп көнләшмим коштан мин.

Рухи чисталык – канатым,
Җилкәнем – әхлак нуры.
Ирлек бирә безгә хөрлек,
Барыр юлыбыз туры.

# ЮЛ ЧАТЫНДА

Кем булырга? Нинди юл сайларга? –
Уйлар өермәсе башымда,
Киңәш ит, дим, әти. Ул елмая,
Яшьлек шул шул, мәңге ашкына.
Минем башым моңа җитәр микән,
Дөнья бүтән, үзгә замана,
Кем булсаң да, улым, хак юл сайла,
Бәхет юлы хак юл санала.
Бу дөньяда бары шул бәхетле –
Кадрен белгән йөзе аклыгын,
Ымсын ризык алга килгән чакта
Саклый белгән намус сафлыгын.
Әти-әни дигән изге сүзне,
Рухи чишмәң кайда типкәнен
Онытмасаң, улым, син кимәссең
Язмышларның кара чикмәнен.
Миннән теләк – ак юл сиңа, балам,
Рәхим-шәфкать бирсен Ходаем,
Исеңдә тот халык мәнфәгатен,
Өмет-хыял, моңын көн саен.
Менә күз сал шушы ябалдашлы
Күпне күргән юан имәнгә.
Тамырлары тирән берекказнгә
Бирешми ул салкын җилләргә.

* * *

Күбәләкнең сарысы бар, кызылы,
Гөл-чәчәкләр бу дөньяда мең төрле.
Табигатьтә бары да камил... һәм серле,
Кеше үзе табигатьнең бер сере.

* * *

Бу дөньяның сигез ягы бар дип,
Кем соң ялгыш фикер тараткан?
Белмәгән ул – Ходай дөнья ягын
Һәр кешегә берне яралткан.

* * *

Тылсымлы алтын балыктан
Көтмик әле могҗиза.
Кемнең кулыннан эш килә,
Язмышына шул хуҗа.

## ХӨКЕМДАРЛАР

Акыл белән хисләр тартышында
Белик дисәк кайда чын хаклык,
Хөкемдарлар гадел каршыбызда –
Намус, вөҗдан, оят, әхлаклык.

## ТӨШ

Искерде, таушалды дипмедер,
Гармунны атканнар чормага.
Тылсымлы, сихерле телләрен
Тузанлы пәрәвез чорнаган.

Күптәнме, җаннарга дәрт биреп,
Ашкынып, моңаеп, мутланып,
Урамнар тутырып, рухланып,
Йөрде ул тормышка сокланып.

Яшьләргә кушылып шатланды,
Туйларда биетте, җырлатты.
Ятимлек күргәндә сулыгып
Сыкранды, елады, елатты.

Хәзер ул коргаксыл, какшаган,
Асыл мал кадере югалган.
Караңгы чормага моң сарган,
Дөньясы бик кысан, тар калган.

...Төн саен бу гармун төш күрә,
Төшенә бик оста кул керә.
Кочаклап, телләргә үрелә, –
Бар җиһан нурларга күмелә.

## ЕЛГА ЗАРЫ

Язгы ташуга елышып,
елга сөйли моң-зарын:
«Җәен билне ярлар кыса,
тураеп булмый, җаным».

Кышын бәкегә зарлана:
«Менә, мә! Хәзер йөгер!
Дөнья җәен иркен икән,
боз кочып үтә гомер».

## МӨҺЕР

Миннән башка кеше кем ул?
Әйтсәм әйтим чүт кенә:
Мин булмасам, бу дөньяда
Барыгыз да чүп кенә.

«Мөһер!» диләр мине зурлап,
Минем сурәтсез генә
Берегез бернишли алмый,
Кадрем белегез менә.

## КЕМ МАКТАУГА ЛАЕК

Саран кеше бик фәкыйрь ул,
китсә дә бик нык баеп,
вакытка сараннар гына
минем мактауга лаек.

## ХАКЫЙКАТЬ

Үлем – сер,
тормыш – табышмак.

*А.С.Пушкин*

Тормыш – табышмак, үлем – сер.
Әгәр ныклап уйласаң бер,
серсез табышмак та булмый,
табышмаксыз сер дә булмый.
Үлем, тормыш бер сыйфатлы,
ул сыйфат МӘҢГЕЛЕК атлы.

## ЙӨРӘК ХӨКЕМГӘ ХАКЛЫМЫ?

Юка гына китап
Укыдым да
Бик сокландым
Кайнар хисе, олы фикеренә.
Шул китаптан көчте
Хыянәткә нәфрәт
Күкрәк читлегемә.
...Йөрәк хөкемгә хаклымы –
Шуны белмим менә.

## УЗДЫРМАСКА ИДЕ

Шаккатабыз еллар агышына,
сизмибез дә вакыт тизлеген.
Бушка гына уздырмаска иде
гомерләрнең һичбер мизгелен.

## ҮЗ МӘНФӘГАТЕ

Тигәнәкнең дә дөньяда
Бар үз мәнфәгате –
Койрыкка ябышып йөрү
Аның яшәү дәрте.

* * *

Син кулыңа каләм алсаң,
Мин язучы булам дип,
Иҗат юлында йөрәкне
Укучыга басма ит.

* * *

Тәмуг салкыннары дибез,
Кышкы суык таңнарда.
Мең мәртәбә зәһәррәк
Салкын була җаннарда.

## КЕШЕ КҮҢЕЛЕ

Нинди иркен дөнья:
диңгез, һава, дала.
Кеше күңеле барыннан да иркен –
Уйлап кына кара.
Кеше күңеле барыннан да таррак –
Күпме сабый бала,
Күпме ата-ана тәрбиясез кала.

## СӨЕНЕЧ

Сукыр тычкан оясында сөенә,
Әле ярый кояш юк дип өемдә.

## ФӘЛСӘФӘ

Былтыргы җил быелгыдан яхшы –
Җимермәде дулап койманы.
Быелгы җил былтыргыдан яхшы –
Ишегалларына сыймады.

## КҮЛӘМ

Җиһанның һәр инсаны –
Ком бөртеге нибары.
Әхлакый нур калдырса,
Һәр кеше ул – Җир шары.

## БОРЫНГЫЛАР СҮЗЕ

Борынгылар белеп әйткән –
Балык башыннан чери,
Көтүчесез сарыкларны
Кәҗәләр ияртеп йөри.

## БЕР АБЫНГАЧ...

Ачысын да, төчесен дә татып,
Яхшы беләм, имеш, дөньяны.
Уңны уңга көйләп йөри торгач,
Килеп чыга, каһәр, сул ягы.

Нык абынгач ялган абруйларга,
Таныйм хәзер алар битлеген.
Ничек күрмәгәнмен – таш баскан ич
Бик күпләрнең күкрәк читлеген.

## ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Үзем елдам да түгел күк,
Җилле дә түгел кана.
Ә күңелем тынгы белми,
Җилкенеп алга чаба.

Туктамый киртә күрсә дә,
Сикерәм дип атлыга.
Дөнья матур, өз тезгенең,
Тик дулама, чап кына.

Акыл әйтә – өзлегерсең,
Сабыррак бул чак кына.
...Йөрәк куша – гомер кыска,
Мин түзәрмен, чап кына.

## САКСЫЗ ГЫНА БЕР СҮЗ ӘЙТТЕҢ

Саксыз гына бер сүз әйттең
Йөземнең суын түгеп.
Бик яралады йөрәкне
Сүзең аткан ук кебек.

Бабайларның сүзе бик хак:
Яхшы сүз – җан азыгы.
Һәр кешедә дә йөрәк бер,
Яман сүз – җан казыгы.

## И ЙӨРӘК...

И йөрәк, картаеп, чәчәктәй сулганчы,
илһамым чишмәсе булсаңчы!
Мәхәббәт, дәрт белән тулсаңчы,
ашкынып, җилкенеп торсаңчы.

Сагышлы җырларны белмичә,
ялкынлы җырларны белсәңче,
хәвефле юллардан йөрмичә,
тап-такыр юллардан йөрсәңче.

Гомернең узуын тоймыйча,
вакытның сулышын тойсаңчы,
тормышны сөюдән туймыйча,
баш иеп яшәүдән туйсаңчы.

## МЕҢЕНЧЕ КӘРРӘ

*(Мәсәл)*

Асыл костюм шуңа бермәл күрсенде –
Эчке күлмәк кәперәйде беркөнне:

«Хуҗабызга кем кадерле, кем якын?
Мин ләбаса! Мин булмасам, кем тагын?

Көне-төне ул минем кочагымда,
Күреп яшим мин ялангач чагын да!

Сиңа тими беркайчан да бу рәхәт,
Сиңамы соң мондый тормыш, бу бәхет».

...Керләнгән, дип, ничек моны күрмәдем,
Салып атты беркөн хуҗа күлмәген.

Елый-сыкрый хәзер күлмәк бичара...
Син, укучым, моңа сабак дип кара.

# Мин әрним, көенәм, уйланам



## НИК ШУЛАЙ РӘСӘЙДӘ?

Соры көн...
Елак күк...
Кысыр җир шәп-шәрә...
Уйга уй бәреләә
Чакма күк бәгырьгә.
Ничәнче мәртәбә
Бу Рәсәй сөрлегә,
Җәмгыять нигезе
Әйләнә төрлегә?
Җир-ана сыкрана,
Улы бит шөкрана
Кыла да чөмерә
Хәмерен, дивана.
Ничәнче мәртәбә
Үзгәреш, түнтәреш...
Рәсәйдә көнкүреш –
Халыкка бимаза.
Чуалыш – чын каза,
Хөрлеккә җеназа.
Ник шулай Рәсәйдә,
Җавабын кем әйтә?

* * *

Нәни генә күлдәвектә
күгәрчен су коена,
Сукбай сулыгып күзәтә,
талып авыр уена.

## ХАКИМ ЗАРЫ

«Ятимнәр күп» дисез, моның өчен
Каһәрләргә күчеш чорынмы?
Мөмкин түгел кана дәүләт буйлап
Сөртеп йөрү һәрбер борынны.

Тотрыклылык үсә, хезмәт хакы...
Электоратка соң ни кирәк?
«Рәхмәт» сүзе бер дә ишетелми,
Канәгатьләр сафы ник сирәк?

Әй сайрыйлар: «бомж бик күп», имеш,
Бомж түгел бездә, сукбайлар –
Ярым хәерчеләр – ярым бай бит,
Киләчәктә матур юл сайлар.

«Салым буа? Салым йорттан куа?
Газ өзәләр?» Тот та салам як!
Берни түләмичә яшим дисәң,
Әнә мәгарәгә кереп ят!

Кем ач анда? Пылау ашасыннар,
Солтан ашы пылау, туклыклы.
«Монетлашкан» илдә «без ач» дию
Хакимият өчен хурлыклы.

## ДУСЛЫК – СЫНАУ

Кем эзләми бу дөньяның гамен
Һәм ясамый яшьли мең хата?
Кем татымый югалтулар «тәмен»
Һәм әрнеми икән шул хакта?

Бер карыйсың – янда иң якын дус,
Аннан башка тормыш юк сыман.
Бер карыйсың – тирә-юнең буп-буш,
Уртак юлыбызда гел томан.

Кая китә дуслар, өмет-теләк,
Зур планнар бергә корганнар,
Авырлыклар килсә, бердәм булыйк,
Без ахирәт дия торганнар?

Дуслык – сынау безнең кайнар канлы
Яшьлегебез сынын, колачын:
Баш аркылы язмыш-пәһлеванны
Чөеп аткан егет – чын лачын.

## ТАТАРГА БИЛ НӘРСӘГӘ?

Егет, шуны әйтсәнә:
Татарга бил нәрсәгә?
Бишкә бөгелергәме,
Йолдызлы каеш салып,
«Бегом!» йөгерергәме?
«Зур абыйча», таянып,
Матлап сүгенергәме,
Көрәшләрдә җиңелеп,
Уфлап үкенергәме?
Миңа шуны әйтсәнә –
Татарга бил нәрсәгә?

## АКЫЛ КЕРГӘЧ

*(Карт чиновник авызыннан)*

Вакыт-вакыт ачы уйга талып,
күптән корган «мин»лек пулатын
шәфкать-ригаясыз ватып ташлап,
үз-үзеңә палач буласың.

Эре булып күренергә теләп,
ник вакландык күпләр каршында?
Чүт эләкми калдык икейөзле
ялагайлар корган капкынга.

«Утлы су»ны синең алга куйган
ахирәт дус булып күренде.
Бик эшлекле, оста хуҗа булып
сүгенгән кем? Үзең түгелме!

Ике кулың һәм аягың булгач,
олы адәм заты, янәсе.
Кәккүк аенда да бүрек кидек, –
Безнең башлар – дөнья бәясе.

Сыртны җиргә тидермибез диеп,
сырт сөяксез булдык еш кына.
Юрга менү теләгеннән янып
шуыштык без – өстән куш кына.

...Киләчәкнең гадел хөкемендә
якты йөзле булыйм дигәндә,
йөрәгеңә юшкын утыртмыйча
яшьнәп яшәү зарур икән лә.

## НИК ТҮЗӘБЕЗ?

Казан бүген моңсу, нәүмиз калды,
ватып аткач изге бинаны,
Гафурилар, Фатих Әмирханнар,
бөек Тукай җаны сыйганны.

Үсәр анда, калкыр яңа бина,
шундый укмы, әллә бүтәнме,
тик аңламыйм мондый хилафлыкка
күзне йомып безнең түзгәнне.

Без битараф, салкын канлы булгач,
телебезне хәтта кисәләр.
Түзәрбезме, мифик дәүләт теле,
татар теле юк ул, дисәләр.

Инде, Тукай сөеклебез, диеп
авыз чайкамыйк ла, зинаһар*,
йөрәгеңнән саркымаган сүздә
сүз зинасы, уйнаш, зина бар.

## ТЕРСӘК ЯКЫН, ТЕШЛӘП БУЛМЫЙ

Исән чакта бирмәгәнмен
Гөл-чәчәкләр әниемә,
Яшьлек хатам җанны талый,
Оялады бәгыремә.
Гафу ит дип чәчәк куям
Әниемнең каберенә.

* *Зинаһар* – зинһар.

## ТАТАРЫМ

**Авызың тулы кан булса да,**
**дошманың алдында төкермә.**

*Халык сүзе*

Авыздагы канны күрсәтмик дип,
Күп чыдадык инде, чыдадык.
Күкрәктәге изге, кайнар ярсу
Вулкан сыман атып чыгарлык.

Камытың сал инде, әй, татарым,
Эшкә җигеп зирәк акылың.
Дөнья тоткан ата-бабаларның
Истә саклап горур асылын.

Татар халкы чыгымчы ат түгел,
Очраса да кире якларың,
Булган ласа хәтта тарихны да
Мөгезеннән тоткан чакларың.

Ак җәймәләр сиңа беркем җәймәс,
Чөнки синең исемең татар бит.
Элсә элсен «кирпеч» шовинистлар,
Юлың гадел – батыр дәвам ит.

Ялгыш кына, сер бирмәскә теләп,
Авызым канамый, юк, дисәң,
Хәтердә нык саклыйк, и татарым,
Көрәшергә килдек, без исән,
Без мәңгегә килдек, без исән!

## БЕЗ КЕМ?

> Ата-аналар балаларын татар мәктәпләренә бирергә теләмиләр.
>
> *Газеталардан*

Кайда безнең кан хәтере,
Тамырыбызда нәрсә ага?
Телебездән колак каксак,
Киләчәккә нәрсә кала?

Кысан рухи тозаклармы,
Сурәт элгән почмаклармы,
Тәһарәтсез кочаклармы,
Мәгарәдә учаклармы?

Җир йөзендә без түмгәкме,
Әллә зәгыйфь бер имгәкме?
Дөнеп беткән этрәк-әләм,
Иләс-миләс җилбәзәкме?

Кем булабыз, таптап йөрсәк
Ана телебез кадерен,
Кайда безнең кан хәтере,
Ата-баба җан-бәгыре!

## СЫНЫҢ БУЛСА...

Ярым шәрәләр тәкрарлый –
Сынлы сәнгать – гүзәллек.
Ярый ла ул сының булса
Сәнгать күзе түзәрлек.

## ЗИЛЗИЛӘ ТӨСЛЕ

Шашынган диңгез дулкыны,
кара болытлар упкыны,
хәбәрсез югалган кораб,
җирдән кубарылган нарат –
җил-давыл эзе.

Чуалган иген кырлары,
өзек якорь чылбырлары,
Челпәрәмә тәрәзәләр,
тузан тулы хәрабәләр –
зилзилә эзе.

...Холкына хуҗа булмаган,
ярсуына чик куймаган,
җәнҗал чыгарып туймаган,
Көч гел гадел дип уйлаган –
зилзилә төсле.

## АҢГА КИЛҮ

Мәчет ачу тантанасы...
Халык бик куанып йөри,
...Күрше авыл урысы да
Мәчет юлыннан кар көри.
Бәйрәмнән соң алып кереп
Чәй эчердем танышыма.
Уртак илдә, уртак җирдә
Әләмнәр дә, адәмнәр дә
Менә шулай алышына.
Һич бирешми шовинистлар
Ярсу, кайнар тартышына,
Үзгәрешләр керә бара
Гасырларның агышына.

## КЫЧЫТКАН КЫЙССАСЫ

Чүплектән туеп,
Бермәл кычыткан
Аланга чыгып
Зур нотык тоткан:
«Әй, алан халкы,
Сезгә сүзем бар.
Тыңлагыз әле
Биреп игътибар.
Мин хәзер бүтән,
Сезне яратам.
Яхшы сыйфатым
Бик күп, санасаң.
Инде мин булыйм
Сезнең патшагыз,
Ә гөлҗимешне
Алып ташлагыз.
Кояшлы урын
Гел аңа тигән,
Чүплек башында
Мин җәфа чигәм.
Мин бу чүплектән
Аланга күчим,
Күмәкләп яшик,
Мин бит тиз үрчим.
Һич томаламам
Кояшны, айны.
Бергә булырбыз
Җыен агайне.
Чәчәк атарсыз
Язын-көзен дә,
Ә гөлҗимешнең
Өзик эзен дә.
Үзе бик чәнчә,
Кызыл җимеше,
Безнеңчә түгел
Йөрәк тибеше...»

Моны ишеткәч,
Зур алан халкы
Бу оятсызлыктан
Нык хәйран калды.
«Без? Гөлҗимешне!
Читкә кагыйкмы?
Һәм җаныбызга
Гөнаһ алыйкмы?!
Синең бар эшең –
Кешене чагу,
Ә эчең тулы
Бик зәһәр агу.
Килмә аланга,
Юхаланма, кит,
Агуыңны син
Тамырыңа сип!»
...Чәчәкле алан
Чәчрәп чыккан,
Чүплек башында
Калган кычыткан.

* * *

Кимсетү ярамый күлне,
Нәни дип, сай дип янә.
Кояш, аны көзге итеп,
Бизәнә, көязләнә.

## ЗАМАН ГАЕПЛЕМЕ?

Адым саен маркет –
бизәкле шешәләр,
узып киттем дисәң,
алдыңа төшәләр.

Күңел ымсындыра
хәмернең иң шәбе,
«мине ал әле» дип тора
коньягы, шәрабы.

Эчтеңме – эчеңдә
шайтаннар котыра,
«сүген, акыр, бәйлән,
син көчле» дип тора.

Айныткычта гына
акыл кайта аңга –
ник эчәмдер, исемем
күмеп ямьсез данга?

Кем мине эчертә
кыстый-кыстый хәмер?
Үземнән ләбаса
үземә үк җәбер.

Болганчык бу заман
игә килми һаман.
Заман гаеплеме,
үземме соң яман?!

## УЙГА ТАЛСАМ…

Уйга талсам, хәтер алып китә
зәңгәр күкле үсмер чагыма.
…Ертык күлмәкле кыз, күрше кызы
күз алдымда даган атына.

Әле җиде, әле җитмеш яшьтә
тирбәлә ул – сихри абага.
Җилфер-җилфер ефәк толымнары
агара да кабат карала.

Бәрхет костюм иңнәренә сеңә,
ертык күлмәк кинәт югала.
Миләш муенсалар алтынлана,
ә йөзеннән илаһ нур ага.

Чеби баскан ялан аяклары
затлы оекларга төрелә,
Күзгә карап, серле, уйчан кызый
чөерелә, көлә, сөенә.

Мин, сискәнеп, каршысына киләм, –
Егыла күрмә, җаным, уф, Алла!
Ә ул чая кочагыма оча,
әби атлы гүзәл кыз бала.

Хәтер очы бик еракка китә –
зәңгәр күкле үсмер чагыма.
Ертык күлмәк кигән күрше кызы
күз алдымда даган атына.

## КАРТ ИМӘН

Карт имән бик күпне күрде, –
Уе айкала,
Иңендәге авырлыктан
Хәтер чайкала.

Ботагында әле һаман
Тешле бау эзе.
Колагында яшь җаннарның
«Хуш, дөнья!» сүзе.

Нәрсә бүлделәр кешеләр
Чулман ярында?
Кылычка-кылыч килделәр
Аның янында.

Яшен атты. Җирне басты
Кызыл төс кенә.
Ыңгырашып ирләр ауды
Гөлләр өстенә.

Кем сикерде шатлыгыннан,
Кем кемне җиңде?
Кем кабергә иң ахырдан
Йә алдан иңде?

Йөзьяшәр имән тирәсе –
Тоташ каберлек.
Гасырлар буе түзәргә
Кирәк сабырлык.

## ДӨНЬЯ БЕЗНЕ АТ ИТКӘН ИЧ

*Фәрит дустыма*

Көлә идең:
«Ат җигә белмисең,
Шул буламы авыл егете!
Болай булса синнән
Конюх чыкмас,
Ат яратмый синең кебекне...»

Өйрәндем мин анысы
Ат җигәргә,
Гарьләндеме шунда яшь күңел,
Чыбыркыны синдәй шәп шартлатып,
Дөнья кудым аннан, ат түгел.

Әллә юкса ул кудымы мине,
Нык камытлап, кысып йөгәнләп,
Йөзләп кенә түгел, җәлләмичә
Мәшәкатен өеп меңәрләп?

Күз ташлыйм да үткән юлыбызга,
Син, күрәмсең, Фәрит, арганбыз.
...Дөнья үзе безне ат иткән ич,
Ә без шуны сизми калганбыз.

## БЕР ЙӨРӘК БИТ...

Иремнең үле хәбәре
Килгәннән бирле туктаусыз
Әрни дә әрни йөрәк.
Инде алтмыш биш ел узды, –
Ә ул сыза, утлы күмер,
Төтенсез генә көйрәп.
Ә шулай да күңел көтә,
Өмет яши, бер кайтыр күк, –
Йөрәк шундый шул, йөрәк.
Җиңү көннәре килгәндә,
Каһарманнар күкрәгендә,
Орден-медальләр күргәндә
Иңрәп сызлый йөрәк.
Сызламасын иде дә бит,
Сызлый, нишләмәк кирәк,
Бер йөрәк бит, бер йөрәк.
Оныгым бит армиядә,
Дөнья хәлен белеп булмый,
Хатлары килә сирәк.
Төннәр буе йоклый алмыйм,
Йөрәкне кайнар ут ялый,
Бер йөрәк бит, бер йөрәк.

## ҖАН КӨЗГЕСЕ

Хәсрәттән дә, шатлыктан да
Күз ник яшьләнә, диләр,
Күзнең җанга аерылгысыз
Береккәнен белмиләр.

## ТӨНГЕ ХЫЯЛ

Күшеккән йолдызлар
Җемелдәми бүген,
Җир-ана юксына
Көләч айлы күген.

Болытлар куера,
Җилләрдән тол калып.
Адашкан көлтә-ут
Юл эзли төн ярып.

Карурман миңгери
Комсыз төн туенда.
Хыялы – тирбәлү
Ал таңнар куенында.

## САГЫНУ

Яшь чак күптән үтте, олыгайгач
Яшермим лә хиснең авырын:
Бик сагынгач чыгып кычкырсам да,
Җавабы юк туган авылның.

Җил иссә дә туган якларымнан
Нидер көтәм, белмим үзем дә.
...Яшьли җан асраган умач ашын
Тансыкладым гомер көзендә.

## ТАГЫН ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Көләч июньдә туганмын,
кояш Кыслага кергәч,
әниемне урман-кырлар
гөлгә, чәчәккә күмгәч.

Дөньяга аваз салганмын
яшисем килеп, елап.
Әни Ходайга ялварган
исәнлек, бәхет теләп.

Күңелемнең йомшаклыгын
белдем шактый үскәчтән,
Кысла аенда туганнар,
диләр, никтер үпкәчән.

Үпкәчән егет бәхетсез,
дигән сүз ялган икән.
Ходай күңелгә тутырып
сабырлык салган икән.

Мөхәммәт табигый тапкан
Әнәсе* хисчәнлеген.
Сәхабәләр мирасыдыр
Минем дә эшчәнлегем.

---

* Мөхәммәт пәйгамбәрнең (с.г.в.) Әнәс исемле ярдәмчесе булган.

## ИЗГЕ ТЕЛӘК

Узган гомер – былтыргы кар ла ул,
үкенмик лә әле, кадерлем,
Дисең дә бит кай көн, ә аннары –
ник белмәдек, дисең, кадерен.

Үткән еллар асыл ташлар түгел,
эз салдылар, дисең, маңгайга.
Ә еш кына өзелеп сагынам, дисең,
яшьлегебез очкан кайларга?

Кайчан гына чәчәк кебек иде...
Тоныкланды инде йөзләр дә,
ә аннары, дисең, җитсәк иде
бергә-бергә алтын көзләргә.

...Кеше шулай мәңге үргә карый,
якты өмет – йөрәк түрендә.
Күк капусы ачык торсын иде
иртәгә дә безгә, бүген дә.

* * *

Пычрак изеп, черек «бүлбе»
эзләвем төшкә кергәндә,
Тешне тешкә шакып, өшеп
уянам эссе бүлмәмдә.

## СИННӘН СОРЫЙМ, ХОДАЙ

Ал таң белән иртән торып,
Синнән сорыйм, и Ходай:
Еллар бирсәң, юллар да бир,
Синнән сорыйм, бер Ходай.

Өйлә җиткәч, күккә карап,
Синнән сорыйм, и Ходай,
Гомер бирсәң, бәхет тә бир,
Синнән сорыйм, и Ходай.

Шәфәкъ баткач, ай калыккач,
Синнән сорыйм, и Ходай,
Гомер бирсәң, бир мәхәббәт,
Синнән сорыйм, и Ходай!

Көне-төне синнән сорыйм,
Рәхимле бул, и Ходай.
Бала бирсәң, тәүфыйк та бир,
Синнән сорыйм, бер Ходай.

Кышын-җәен күңелем синдә,
Син шәфкатьле, и Ходай.
Гомер бирсәң, саулык та бир,
Синнән сорыйм, бер Ходай.

* * *

Сукыр лампа диеп кимсетмәгез,
халыкка ул белем юлы ачты.
Аның сыек яктысыннан өркеп,
Мильон аңнан караңгылык качты.

## МИН ХАКИМ ДӘ, КОЛ ДА

Мин зур хаким – язмышыма хуҗа
Тормыш кырын сөреп йөрергә.
Һәм кол да мин, чөнки саф вөҗданым
Хуҗам булды минем гомергә.

## ГАЙБӘТЧЕ

Ул өрә дә өрә,
Пычрак ниятеннән
Пәрәвезләр үрә,
Хакыйкать «яклый»,
Имеш, үзенә күрә.
Бер шешә күрсәтсәң,
Әти-әнисен сатарга
Йөгерә. Өлгерә.
Белгәннәр, күргәннәр,
Җирәнеп,
Битенә төкерә.
Ул оялмый,
Өрә дә өрә,
...Аннан – сак бул!
Бугазга сикерә.

## УЗГЫНЧЫ

Килеп чыкса кинәт болыт
Көтмәгәндә тын күгемдә,
Дус дигәнем юкка чыга,
Шуңа аптырап йөрим дә

Аннан аңлыйм, дус булмаган,
Узгынчы булган ул бары.
Таный калсаң шундый «дусны»,
Йөрәгең ачмавың ярый.

Теләктәшлек һич көтмәгез,
Андыйлар бит салкын канлы –
Кешеләргә бик битараф,
Узгынчы «дус» котып җанлы.

## ТАШ ТҮГЕЛ

Мәрхәмәтсез, таш бәгырьле,
диләр кайбер кешегә.
Таш түгел, кеше гаепле –
йөрәге туң, өшегән.

Туган йортың, туган җирең
ерактан да якынмы?
Ата-бабаң кабер ташы
җылымы ул, салкынмы?

Салкын йөрәк – ит кисәге,
кереп посса күкрәккә,
Ялгышмыйк ла, ташта түгел,
бөтен гаеп йөрәктә.

# Мин шаярам, көләм



## ШҮРӘЛЕНЕҢ КАЗАНДА КҮРГӘННӘРЕ

Борын-борын заманда дип сөйләп тормыйм бик озак,
Беркөн килгән башкалага бик тә сәер, шикле зат.

Ир-атмы бу? Алай дисәм, алдашу, ялган булыр,
Хатын-кыз да түгел, имеш, күргәннәр хәйран булыр.

Ярар инде, ялыктырмыйм, әйтим, килгән Шүрәле,
Йончып беткән, ә шулай да уенда үч, күр әле.

Шүрәленең үз уенча, бу дөньяда даны бар –
Тамырында Былтыр кыскан Шүрәленең каны бар.

Илләр гизеп, озак эзләгән – ай түгел, еллар буе,
Былтырны табып үч алу аның нияте, уе.

Хуш, болары калып торсын... Ул Казанда ни кыра?
Чүплек савытын актарып, тамак ялгарга тора.

Сискәндерде шулчак өне пәйда булган сукбайның:
– Калдык-постыгын эзләмә, братишка, тукларның.

Таныйм да күк, танымыйм да, без бер ише түгелме?
Хәер, хикмәт андамыни, тетрәндерден күңелне.

Казынмәле, мә биш йөзлек, миннән булсын изгелек,
Бик өшәнгәнсең син, брат, сак бул, куйма өзлегеп.

Ашап кил син ашханәдә, табигатьнең «хөр» колы,
Чучка шашлыгы сыпыртып, кой шунда кока-кола.

*

Кулына акча эләккәч, йөгерде чатыр-чатыр,
Ашханәгә кергәч, мәхлук нинди хәйләләр корыр?

Сукбай әйткән йортны тапты. Бу ни?..
Бу бит казино!
Шүрәле ялгышып керде алдау-йолдау базына.

Монда аңа игътибар да, күз дә төшерүче юк,
Бәгъзе чырайсыз, бөрешкән,
бәгъзе нәкъ әтәчтәй кук*.

Кайсысы ах та ух килә, кулын уа кайсысы,
Һәрберендә акча-акча-акча оту кайгысы.

Карап торгач калай күзле бәндәләргә аз гына,
Әпен-төпен чыгып чапты, тагын чүптә казына.

*

Тамак ялгап килеп чыкты бу Бауман урамына,
Яшьләр икән монда, ай-һай, сыраны «ура» гына.

Егетләрме бу, кызлармы, охшашканнар, йа Хода!
Ыштаннары кай җиренә, ничек эленеп тора?

Чәчләре озындыр бик, күлмәкләре кыска гына,
Шәп-шәрә корсак вә кендекләре күренеп тора.

Ул кендекләр, мин сиңайтим, пыяладай шоп-шома,
Шүрәлебез хәйран калды, бик аптырады шуңа.

Яшь кенә кыз дигәннәрнең корсагында ялт та йолт
Нәрсәләредер җемелди – хәя* дә юк, оят та юк.

Егетләрнең чәче ялдай, күрмәгәнең күр менә,
Ә кайсысы такыр башлы, түбәдә кикрик кенә.

---

* *Кук* – кукрайган, масайган.
* *Хәя* – оят, намус.

Сөйләшәләр икән болар, ни гаҗәп, чат урысча,
Татарча сүз урысчага ярты-йорты кушымча.

Бу урамда почмак саен кыргый тавыш яңгырый,
Шул тавыштан тәрәздәге пыялалар шалтырый.

Чиккә җитте Шүрәленең шул шау-шудан каушавы,
Җәһәннәм тавышы бу, ди, һич түгел урман шавы.

Гаҗиз булды Шүрәлебез, төшме, өнме, аптырый,
Урманын сагына, мескен, курка, дер-дер калтырый.

Шул чагында урап алды яшьләр урман сарыгын:
– Кая куйган бревноны, ничек ачкан ярыгын?

Авызларында сигарет, пошкырталар пош та пош,
Шүрәлегә сорау ява: «Вау, дружище, ни йомыш?

Ничек, каян килеп чыктың? Когда из лесу качтың?
Былтырның агач замогын син когда, ничек ачтың?

Скажи свое имя, каян килдең син, нәрсәгә?
Маңгаеңдагы мөгезне как вырастил, өйрәтсәнә.

Классный парень, диде берсе, иди ко мне, матурым,
Син сегодня безгә иптәш, исемең булыр Сатурн.

Кайсы әйтә, юк инде, ди, назовем-ка Шурулла,
Кайсы әйтә, юк-юк, Шурик! Нур өстенә нур була.

Йә булмаса Шур-Алекс диеп исем куярбыз, ди,
Ә йоныңны зеленыйга, зәңгәргә буярбыз, ди.

Алып барыйк «Арена»га – стриптизга –
йоны чук-чук,
Ул ялангач, димәк ки, чишенеп тә торасы юк.

«Пирамида»га, ди берсе, илтик бик тиз бергәләп,
«Йолдыз» булып йөрсен әйдә, маймылдай сикергәләп.

Нет, ди берсе, давай запрем зоопарк читлегенә,
Без – «крыша», салым салыйк, надо найти
читлек кенә.

Чибәр кызлар каш сикертә, уйныйк дип кети-кети,
Рубль булса, досуг бездән – хет Шүрәле,
хет син йети*».

Кул сузарга өлгермәде кызларга Шүрәлебез,
Тегеләр үзе кытыклый месkenне, күрсәгез сез.

Үз акчасына сыйлыйлар, сырасына мәй салып,
Биеттеләр шукланып, егылганчы арып-талып.

Каптырдылар сигарет та: «Әмрикәдән? «Мальборо»!»
Батыраеп китте, мәхлук, менә шайтан алгыры.

Исенә төште максаты – Былтырны эзли кана,
Батырга исрек аузыннан каргыш вә ләгънәт ява:

Мәрхәмәтсез, ләгыйнь ул, алдап котылган куркак, ди.
Үзем шунда булмадым, сытадыр идем шулчак, ди.

Акырыпмы-акыра, ничек кенә үрсәләнми,
Мин аны эзләп тапсам, күрмәгәнен күрсәтәм, ди.

Шулчак каян калыкты бер әзмәвер җитез генә,
Былтыр гына түгел бу – аюмыни симез генә.

Богау салды шундук ул Шүрәленең кулларына,
Айныткычка хәзер үк илтү моның уйларында.

---

* *Йети* – борынгы кыргый кеше (снежный человек)

Алып китте җилтерәтеп исерекне машинада,
Тимер челтәр тәрәздә, кул богаулы – качып кара!

Шур-Алекс өзгәләнә, менә тагын килеп капты,
Сугып төшергәч тешен, инде дәшми, аузын япты.

Ай-ваена карамый, кул-аягын бәйләп куеп,
Иләделәр мескенне туктаганчы арып, туеп:

– Урман сатканс ыңдыр бит, кая яшердең акчаңны,
КПЗда утырырсың, без акчаңны тапканчы.

Ярый әле күршегә туры килде теге сукбай,
Төнлә бауны чәйнәп өзде: чап, дускай, давай, гудбай.

Алны-артны, уңны-сулны хәзер белә Шүрәле,
Урамнардан урманына әй элдертә, күр әле.

Үзе һаман тәкатьсез кабатлыйдыр бер үк сүзен:
– Моннан соң, – ди, – бу якларны күрмәсен сыңар күзем.

Халык хәзер бүтән икән, бик үзгәргән бу якта,
Барча урман халкын җыеп сөйләрмен, – ди, –
шул хакта.

Рәхмәт яусын изге җанлы, миһербанлы сукбайга,
Бәхет басып, аның юлы чыксын иде уңайга.

Былтырдан да үч алу теләгемнән кире кайтам,
Урманымда гына яшим, өн ясап кереп ятам.

## ТӘКЪВА ЭШМӘКӘРГӘ

Калган чәчне уңга-сулга тарап
Каплама ла такыр башыңны,
Бисмилла дип хәләл ясап булмый
Кеше хакын – хәрәм ашыңны.

## КИЛДЕ-КИЛДЕ ХАЛЫККА «ВЛАЧ»

Килде-килде (ур-ра!) халыкка «влач»,
Сайлау җитсә, җәя сәяси колач,
Алдан ук белә – кем була патша,
Ә хакимлек итә дәүләттә акча.

## ЭРЗАЦ

Экраннарда игълан: «Чакыр, киләм
фатирыңа коштай очып кына.
SMSка җибәр, чибәр егет,
сөешербез икәү качып кына».

Тыңкыш егет сәхнәләрдән төшми,
еллар буе «салкын чәй» эчерә.
Җыр ләззәтен татымаган килеш,
мисс «йолдызлар» гыжлый бар көченә.

Зыр-зыр итә янда «поддержка»,
ава-түнә, бөгелә, сикеренә.
«Йолдыз»ның да эше харап икән,
нуры сүнә, калса үзе генә.

## ОФЫК

Тау башыннан офык киңәя дә –
Менәсе бар анда, менәсе.
Менгәч тә бит башы әйләнгәннәр
Аска оча, әттә генәсе.

## КАПКА

Көндез капкаңа сугылдым,
Бикле иде капкаң.
Кичен килеп каккан идем,
Кат-кат бикле, баксам.

Ачык капка – ачык күңел,
Бикләп торсаң – тозак.
Үз-үзеңә рухи киртә,
Үз-үзеңә йозак.

## НИК ШУЛАЙ...

Ни хикмәт, ник шулай? Гомерләр
сизелми ага да агалар.
Чибәрләр көннән-көн күбәя,
тик менә ерагая аралар.

Белмисең кайсына карарга,
сокланып, куанып... Йа Ходай?
Ә менә мәхәббәт шигырем
күңелдә аз шыта, ник шулай?..

## КОДАЛАРДАН БИК УҢДЫМ

Ике-өч көннең берендә
Кодагыем түремдә,
Мунча ягам, бәлеш салам –
Рәт белмәслек түгел лә.

Ул үзе дә итагатьле,
Күчтәнәче кулында,
Бик бәхетле булдым әле
Карый тормыш юлымда.

Килгән саен алып килә
Балын, чәен, шикәрен.
Кодагый, дип өзелеп тора,
Матурым, ди, чибәрем.

Тик бер сәер гадәте бар –
Сүзе саен күз кыса,
Миңа түгел, минем картка,
Ә тегесе тиз кыза.

Әйдә әле, кодагый, ди,
Вальска биеп алыйк,
Баш әйләнсә, саф һавага
Чыгып йолдызлар саныйк.

Нинди йолдыз саныйлардыр,
Ияреп чыксам, оят сыман.
Юк, көнләшмим, тик эч поша,
Сиздермим, эчтән тынам.

Хәер, җаен таптым, мин дә
Күз кысарга өйрәнәм.
...Кода килгәч, йолдыз санап,
Кочагында кинәнәм.

## СИМЕЗ ҮРДӘК

Симез түшкә, чалыш аяк,
Алдында гел мул тагарак.
Капкан саен аңа булсын
Майлы калҗа – тәмлетамак.
Кызыл чырай, үткен томшык,
Яшь бәбкәләр, тормый шыңшып –
Бак-бак дисә, килә очып,
Рәхәт чигә үбеп, кочып.
...Көтмәгәндә менә шунда
Баш очына тилгән куна.
Симез үрдәк коты чыгып
Калтырана, өши, туңа,
Бәргәләнә, аптырагач,
Арты белән суга чума.

## ТӘҮБӘ

Каһәр генә суксын, өченчекөн
Диңгез булган миңа тубыктан.
Дүрт аяклап кайтып килгән чакта,
Бер өер эт миңа юлыккан.

Койрыкларын ботларына кысып,
Шылганнар бит капка астына,
Бүре булып Айга улаганмын –
Чакматашка тот та бас кына.

Җаным-бәгърем! Бетте! Моннан соңмы?!
Тәүбә инде, тәүбә, кәнишне!
...Иртәгә дә берәр ярты алмаса,
Тотып ярам хәсис кайнишне.

## «ЙОЛДЫЗ»ГА ЯРДӘМ КИРӘК

*(Елмаеп-көлеп кенә)*

Җыр тыңлап хозурланыйм дип
Барсам концерт залына,
Сәхнәдә «йолдыз» саргая,
Тыңлаучыга ялына.

– Зинһар, табыгыз шуны, – ди...
Төштә генә егете
Килеп-китеп йөри икән,
Өзелгән бит өмете.

Бер күрүдә гашыйк иткән
Үткән атна кибеттә,
Үбеп киткән, исемен дә
Сорамаган, чикерткә.

Сак-Сок елап үләр иде,
Белсә аның моң-зарын.
Менә хәзер нишләсен ул,
Каян тапсын шул ярын?

Тамашачылар елашып
Тезелделәр чиратка,
Хатын-кызлар урамнарны
Өләштеләр ир-атка.

Илермәсен, тилмермәсен
«Йолдыз»ыбыз дип менә,
Чыгып чаптык шул егетне
Табарга дип тиз генә.

Әй, укучы, син дә булыш
Эзләшергә, әйдәле,
Мундштук капкан, алка таккан,
Сакал баскан бәндәне.

## МАРКЕТ АЧТЫМ

Супермаркет, бутик, минимаркет,
Субконтинент... Тагын әллә ни...
Көнбатыштан кайчан кереп тулды,
Чиркандыра, тфү, валлаһи.

Ялтыравык бизәк-мәрмәр таштан
Маркетларның дивар, идәне.
Чит илләрдән ага импорт-товар,
Үзләреннән артык дигәне.

Халык-ташкын керә, карап йөри,
Тел шартлата – це-це! Вәт, малай!
Түлә долларыңны, евро түлә,
Барысы да сиңа, ал давай.

Күпләр чыга башын түбән иеп,
Эчтән генә ярсый, сүгенә.
Ике-өч ел акча җыйганнан соң
Килермен дип, кайтыйм бүгенгә.

Ишек төпләрендә әби тора:
Көнбагыш ал, сыңар сигарет.
Кесә төбең капшап таба алсаң,
Ертык рубльләрең чыгарып.

Мин дә менә маркет ачтым әле,
Халык йөри! Гаҗәп, тамаша.
«Лапотьмаркет» диеп исем куйдым,
Сатып ятам ясап чабата.

* * *

Кая китте яшьлек елларым дип,
Уфтанырга кирәкмидер, юктыр.
Бездән тормый вакыт агышлары,
Быелгыбыз – тоелгысыз былтыр.

## КАЧАМ ӘЛЕ

Бик әлсерәп,
   ачы көлемсерәп,
картлык килә
   аягын сөйрәп.
Ә мин карыйм аннан
   тиз-тиз качу ягын,
      килмим якын.
Минем ышанычлы сагым –
   хезмәтем,
Картлык – тынгылык
   янымда йөрмәсен,
хәйләсен, мәкерен
   юлыма тезмәсен.

## ҖИТМЕШ ЯШЬЛЕКЛӘР МАНИФЕСТЫ

Әй, чибәркәй!
Чәчкә карама син,
Җитмештә дә йөрәк яшь әле.
Чәчкә тотып йөгереп киләм, дәшсәң,
Кил, егетем, диеп дәш әле.

## АШЫКМА ӘЛЕ, КАРТЛЫК

Чәчләремә көмеш ука чәчә,
Боектырыргамы күңелне,
Аякларга герләр тагып килә,
Мур кыргыры, картлык түгелме?

Юктыр-юктыр, әле кайчан гына
Сөям дигән карчык кем әле?
Алар шулай сөям дип торганда,
Ашыкма әле, картлык, син, яме.

* * *

Җырлаганда биим диеп
Сикерүең нәрсәгә?
Ата каз да бии белә,
Тик менми бит сәхнәгә.

## ЙОЗАК БЕЛӘН АЧКЫЧ

*(Мәсәл урынына)*

Ачкыч никтер борын чөйде беркөнне,
Бик масаеп, Йозагыннан ул көлде.
Диде: «Син иреккә богау салучы
Һәм үзеңә шуннан ләззәт алучы.
Ә мин – Ачкыч! Мин бит сине ачучы,
Кысу-чикләү, җәберләүдән качучы...»
«Ха-ха! – булды моңа Йозак җавабы, –
Карап торам, син ник шулай һавалы?
Болгатмачы, зинһар, минем күңелне,
Бикләүче кем? Син соң үзең түгелме?»

## КАРТАЙДЫМ ДИП УЙЛАМА

Агарды чәчем дә,
Җитмештә яшем дә,
Картайдым инде дип
Уйлама.

Яшь түгел, чәч түгел,
Хөсетлек, көнчелек
Картайта кешене
Дөньяда.

Эш сөйсә кулларың,
Уң булса юлларың,
Син гел яшь сабыйдай,
Килгән күк дөньяга
Өр-яңа.

## КЫШ ОЯЛСЫН ДИП…

Бураннарга йодрык селкеп
көтәм язлар җиткәнне.
Аннан үзем бик үкенәм –
кыш үпкәләп киткәнме?
Килми дә килми суыклар,
яңгырлы декабрьләр…
Алтын кояш, көмеш карлар
быел, һай, тәкәбберләр.
Көтә-көтә бик зарыккач,
туным киеп өстемә,
Яңгыр димим, чыгып китәм,
кыш оялсын печтек кенә.

## БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ – ЗУР ТЕАТР

Безнең тормыш – зур театр,
Без – артистлар шавыннан.
Елап-көлеп тора маска
Дөнья чаршавыннан.

Берьюлы уйнала монда
Драма, комедия.
Барыбыз да төп рольләрдә,
Вак рольгә дә без ия.

Адым саен монда башлам,
Адым саен чишелеш,
Кульминациягә иярә
Бик еш кына чи килеш.

Режиссеры кем дисәгез,
Анысы да үзебез.
Тормыш дигән тамашада
...Клоуннар төсле без.

# Җырлыйк әле бергәләп



# БИЕКТӘ ГЕНӘЙ ТАУНЫҢ, ҺӘЙ, ТҮБӘСЕ

*Л.Батыр-Болгари* көе




A♭/E♭
E♭7
A♭
Fm
Fm/E♭
га ни-чек тү - зә - се.
Жап-кай - жа-наш кы-на са -
D♭
Bm7
A♭/E♭
E♭7
гын - ды - ра — саг(ы) - ну - лар - га ни - чек тү - зә -



1.
A♭
B♭9/E♭
A♭
mf
//ce.
2. Би -
mf
2. A♭
Cm
D♭
сеп.
mf
agitato
3
3
3


Cm D♭ Fm
Кав(ы)-шал-мый-быз ди-еп әй-
Cm7 D♭ A♭/E♭ E♭7 A♭
тә күр-мә, сү-зең ка-бул бу-ла күр-мә-сен.
B9/E♭ E♭7 A♭ 3. A♭
3. Би- //ры. Төш-
Fm D♭
лә-рем-дә ки-теп ю-га-ла-сын, өзә ү-




Биектә генәй тауның, һәй, түбәсе,
Ат чаптырып кына, әй, менәсе.
Җанкай-җанаш кына сагындыра –
Сагынуларга ничек түзәсе.

Биектә генәй тауның башларына,
Колмак утырттым ла, әй, үрләсен,
Кавыша алмыйбыз диеп әйтә күрмә,
Сүзең кабул була күрмәсен.

Биектә генәй тауның, һәй, чишмәсе,
Агадыр ла, ага көмеш сулары.
Төшләремдә китеп югаласың,
Өзә үзәкләрне шулары.

# ГОРУР БӨРКЕТ

*Л.Батыр-Болгари* көе




Вокализ ❋) билгедән соң ❋❋) билгегә кадәр 2нче куплетта башкарыла.
Вокализ от знака ❋) до знака ❋❋) исполняется во 2-м куплете.


A♭
Cm7
D♭
кын - нар-га сик(е)-реп ка-нат җә-я коз-гын тү-гел, бөр кет ба - ла -
ме - нә-се и - де тау ба - шы-на, кош-лар ке - бек, их,бер о - ча -
А -
А -

**Кушымта:**


E♭7sus
E♭7
Fm
Fm+7
B9
mf
сы. Би - ек тау-да бөр-кет о - я - ла - ры, таш кы-я -
сы.
✻✻)
о - я - ла - ры,


A♭/E♭
Csus
C7
Fm
F♮+7
да — бөр-кет ба-ла-сы. Дөнь - я - да го-рур бөр-кет бу-
А -
А -
B9
D♭
E♭sus
лып, һа-ва я - рып я-шәп ка-ла - сы.
А -
8va
E♭7
f
Bm9
E♭7
Cm7
А -
А -
А -
f


Fm7
Bm9
Bm/E♭
E♭7
Го-рур бөр-кет бу-лып я - шәп ка - ла- сы.
A♭maj
A♭/G
Fsus
F9
ff
Bm7
А -
А -
ff
E♭sus
E♭7
Cm7
Cm7/F
Fm
А -


Bm7
Bm7/E♭
E♭7
A♭
Го-рур бөр-кет бу-лып я - шәп ка - ла - сы.
D♭/A♭
Bm9
E♭7
mf
2. Кар - //шәп ка - ла-
А -
A♭
D♭maj
rit.
D♭m7
A♭maj
сы.
А-
rit.
8va
л.р.

Зәңгәр киңлек, иксез-чиксез киңлек,
Каурый болыт – бөркет дөньясы.
Упкыннарга сик(е)реп канат җәя
Козгын түгел, бөркет баласы.

К у ш ы м т а:
Биек тауда бөркет оялары,
Таш кыяда – бөркет баласы.
Дөньяда горур бөркет булып,
Һава ярып яшәп каласы.
А-а-а...
Горур бөркет булып яшәп каласы.

Карурманда бөркет ояламый,
Таш кыяда бөркет оясы.
Әй менәсе иде тау башына,
Кошлар кебек, их, бер очасы.

К у ш ы м т а.

## МӘҢГЕЛЕК ЮЛЫ

*С.Ибраһимов* көе






Чал тарихның гадел бизмәнендә
Сират кичә безнең батырлар.
Илнең авыр, бик хәвефле йөген
Иңнәренә салган асыллар.

Кушымта:

Ирләр – изге Ватан таянычы,
Сезгә бәйле якты өметләр.
Гөлбакчалар ясыйк илебездән,
Корычтай нык, горур егетләр.

Халык гамен рухи канун иткән
Пәһлевандай батыр уллар бар.
Туган илен давыл, гарасаттан
Саклап калган ныклы куллар бар.

Кушымта.

Илләр даны ирләр иңнәрендә,
Сыгылмасын гына билләрең.
Арыслангдай ирләр мәңгелеккә
Иңнәрендә илтә илләрен.

Кушымта.

# СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ

*Л.Батыр-Болгари* көе




Соло (женский голос)
Кушымта:
F Gm B Dm7 Gm
mf
Гасырлар-
зе са-гыш-лы, ү-зе са-гыш-лы.
мужской хор Гасырлар-
B F/A Gm7 F B
Соло
Хор
дан Сөем-би-кә ма-на-ра-
дан га-сыр-лар-га кил-гән ил-че— Сөем-би-кә ма-на-ра-
F Cm Gm/D Cm Gm/D Cm F
сы. Хал-кы-быз-ның тиң-сез мә-хәб-бә-те, кү-
сы. Хал-кы-быз-ның тиң-сез мә-хәб-бә-те, кү-


B F Gm E♭/F B F/C
це - лем-нең йө-рәк я - ра - сы. Сө - ем-би - кә,
це - лем-нең йө-рәк я - ра - сы. Сө - ем-би - кә,
B/D F B E♭ F B/D
Сө - ем-би - кә ма-на - ра - сы. Га-сыр-лар-
Сө - ем-би - кә ма-на - ра - сы. Га-сыр-лар-
Cm Gm/D Cm/E♭ Gm/D Cm7 F B Dm7
дан кил-гән Сө-ем - би-кә – хал-кы-быз-ның йө-рәк я - ра-
дан кил-гән Сө-ем - би-кә йө-рәк я - ра-
F
дан кил-гән Сө-ем - би-кә – хал-кы-быз-ның йө-рәк я - ра-


1.
Gm
F/G
Gm
Dm/F
Gm
F
E♭/G
сы.
сы.
Cm/E♭
B/D
F
Gm
E♭
F
Gm
E♭
F
Кода
2.
Gm
F7
B
E♭
//сы.
Сө-ем-би - кә,
//сы.
Сө-ем-би - кә,


Cm7 F7 B E♭ Fsus F7 p sub.
Сө-см-би - кә ма-на - ра - сы – хал-кы-быз-
Сөем-би - кә ма-на - ра - сы.
Cm Gm/D Cm/E♭ F B F
ның тиң-сез мә-хәб - бә-те, кү - ңе-лем-нең йө-рәк я - ра-
p sub.
Gm Dm/F Gm Cm B Cm Gm/D Gm Cm F
сы. Хал-кы-быз - ның тиң - сез мә-хәб - бә - те,
Хал-кы-быз - ның тиң-сез мә-хәб - бә-те, хал-кы-быз-




Зәңгәр күккә ашкан алтын аең,
Иңнәреңә салдың чал тарихны.
Казан үзәгендә балкый Сөембикә:
Үзе горур, үзе сагышлы.

К у ш ы м т а:

Гасырлардан гасырларга
килгән илче –
Сөембикә манарасы.
Халкыбызның тиңсез мәхәббәте,
Күңелемнең йөрәк ярасы.
Сөембикә, Сөембикә манарасы...
Гасырлардан килгән Сөембикә –
Халкыбызның йөрәк ярасы.

Тыйнак, гүзәл, мәгърур Сөембикә,
Бер карасаң – ярсу, газаплы.
Үрсәләнә, әрни моңлы патшабикә,
Кочагына алып Казанны.

Кушымта.

Ал таңнарда балкый алтын ае
Башкалабыз Казан күгендә.
Җырга әверелгән моңлы Сөембикә
Халкыбызның йөрәк түрендә.

Кушымта:
Сөембикә, Сөембикә манарасы –
Халкыбызның тиңсез мәхәббәте,
Күңелемнең йөрәк ярасы.
Халкыбызның тиңсез мәхәббәте,
Халкыбызның йөрәк ярасы.

## САБЫР ИТ, САНДУГАЧ, САЙРАМА

*Л.Батыр-Болгари* көе




та- ба ал- мыйм, ка-я куй-ган- мын.
Эз- ли-эз-ли ай - лар,
ел-лар ү-теп кит - те,
яшь-лек яд-кә-рем-не жуй-ган -мын.
Эз - ли-эз-ли ай - лар,
ел-лар ү-теп кит - те,
яшь-лек яд-кә-рем-не жуй-ган-
мын.
Са - быр ит,
сан - ду - гач,
са - быр ит,
сай - ра - ма,
күң -лем-
Pio mosso


Fm7 Fm7/B B7+5 Gm7 C-9 Fm7 A♭/B
дә - ге я - ра я - ңа - ра. Яшь-ле-гем-нең жы-рын си-ңа
E♭ Gm7 A♭maj Fm7 Gm7 1. Cm7 C-9
жыр-лар и - дем, сал-кын жил-ләр кер-де шул а-ра-га.
Fm7 B7 E♭ G7 A♭
Сал-
Fm7 Gm7 1. Cm A♭ 2. Cm7 G♯7
кын жил-ләр кер-де шул а - ра - га.


mf agitato
3.Нур - лы йөз-ләр күп-тән уй-чан-лан-ды, кав(ы)-ша ал-ма-дык. Без-нең а-ра-
да сал-кын җил-ләр и-сеп, а-е-рып а-лып кит-те,
си-не-да-ла,ми-не-ка-ла-га. Сал-кын җил-ләр и-сеп,
Кушымта:
f
а(е)-рып а-лып кит - те, си-не-да-ла, ми-не-ка-ла-га. Са-быр


ит, сан-ду-гач, са-быр ит, сай-ра-ма, күң-лем-дә-ге я-ра я-на-
ра. Яшь-ле-гем-нең жы-рын си-ңа җыр-лар и-дем, сал-
кын жил-ләр кер-де шул а-ра-га. Яшь-ле-гем-нең жы-рын си-ңа
җыр-лар и-дем, сал-кын җил-ләр кер-де шул а-ра-га. Сал-




Сиңа чиккән бүләк яулыгымны
Таба алмыйм, кая куйганмын.
Эзли-эзли айлар, еллар үтеп китте,
Яшьлек ядкәремне җуйганмын.

К у ш ы м т а:

Сабыр ит, сандугач, сабыр ит, сайрама,
Күңлемдәге яра яңара.
Яшьлегемнең җырын сиңа җырлар идем,
Салкын җилләр керде шул арага.

Мөмкин булса, яшьлегемә кайтам,
Күбәләктәй җилпеп канатым.
Иңнәреңә кунып мәңге калыр идем,
Мин бит сине өз(е)леп яраттым.

К у ш ы м т а.

Нурлы йөзләр күптән уйчанланды,
Кавыша алмадык. Безнең арада
Салкын җилләр исеп, аерып алып китте,
Сине – дала, мине – калага.

К у ш ы м т а.

# СӨЕЛӘСЕМ БАРДЫР ЙӘ СӨЯСЕМ...

*М.Имашев* көе






Романтикмы соң мин, хыялыймы? –
Әле һаман очам төшемдә.
Инде юк бит «сөям, сөям» диеп,
Җилкендереп торган кешем дә.

Ә шулай да төшләремдә очам,
Кул-канатым җилпеп биеккә.
И ашкынам горур бөркет сыман,
Ал таң сызган офык, киңлеккә.

Зәңгәр күк гөмбәзе, кояш өстә,
Яшел хәтфә кырлар түбәндә.
Ә мин очам, алга, күккә очам,
Каурый болытларны үбәм дә.

Рәхәт төшне олы хискә юрыйм,
Өннәремдә уйга талам да.
Сөеләсем бардыр йә сөясем –
Төшләремдә очам һаман да.

# БАЛАЧАК

*Ф.Хатипов* көе






Балачакта бик үсәсе килә,
Атлыгасың тизрәк үсәргә.
Мәктәптә дә тизрәк, һаман тизрәк
Югары сыйныфка күчәргә.

К у ш ы м т а:
Үсмер чакта сиңа канат үсә,
Хыял канатлары – очарга.
Киләчәгең ожмах. Теләк изге.
Дөнья шундый матур кочарга.

Тормыш яме – әнкәй җырларында,
Үс, балам, дип сөеп җырласа.
Назлы кулы белән баштан сыйпап,
Йөрәгенә кысып йокласа.

К у ш ы м т а.

Гүзәл, кайнар мәхәббәте белән
Ямьгә чума яшьлек еллары.
Дөнья нурлы, күктә кояш балкый,
Җырлап тора күңел кыллары.

К у ш ы м т а.

# ЯЛГЫШАСЫ КИЛӘ ЙӨРӘКНЕҢ

***Ф.Галәмиев*** **көе**




**Еллар узды, ерак калдың, дисәм,**
**Үземә мин үзем ышанмыйм.**
**Мәхәббәткә аралар юк диеп,**
**Күң(е)лем белән сиңа очам мин.**

**К у ш ы м т а:**

**Әле һаман хыял канатында**
**Очрашырга өмет-теләгем.**
**Мәхәббәткә аралар юк диеп,**
**Ялгышасы килә йөрәкнең.**

Еллар узды. Акыл белән аңлыйм –
Син еракта, гомер үтелгән.
Еллар аша тормыш йомгагы да
Шактый тәгәрәгән, сүтелгән.

К у ш ы м т а.

Йөрәгемнең ялгышасы килә,
Тыңламыйча салкын акылны.
Сөеп, көлеп, сулык-сулык тибә,
Рәхәт таба шуннан, ахыры.

К у ш ы м т а.

## ГӨЛСИНӘ

*Ф.Галәмиев* көе



Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлсинә.
Мәхәббәттән шашаммыдыр –
Күңелемдә син генә.

Кушымта:
Гөлсинәм – аем, кояшым,
Юлларыма гөл сибә.

Күңелләрем гел синдә лә,
Бәхет кошым, Гөлсинә.
Сөюемне әйтә алмыйм,
Күзләремнән бел син, ә!

Кушымта.

Бөтен дөнья гүзәллеген
Сиңа биргән, Гөлсинә.
Йөрәгемне ничек басыйм,
Киңәшеңне бир син, ә!

Кушымта.

## СИННӘН СОҢ

*Ф.Хатипов* көе






Көн буе өзлексез кар ява,
Синнән соң бозылды һавалар.
Килдең дә ник киттең яңадан,
Яңартып күңелдә яралар.

К у ш ы м т а:

Әйтелмичә калган сүзләр күп,
Мин сине һич күреп туймадым.
Кышкы төн бик озын, таң атмый,
Өзелми, югалмый уйларым.

Йөрәк бит өметсез яшәми,
Син киткән юлларга карыйм да
Җаныма ут яккан карашың
Артыннан барам да, бармыйм да.

К у ш ы м т а.

Юлларың – җепшек кар, бер эзсез
Эри дә югала, югала.
Шык та шык тәрәзәм кагарга
Тагын шул бер елак җил кала.

К у ш ы м т а.

Көн буе өзлексез кар ява,
Синнән соң бозылды һавалар,
Ник килдең, алырга килмәгәч,
Яңартып күңелдә яралар.

К у ш ы м т а.

# ПЕСИЛЕ ТАЛ

*Ф.Хатипов* көе




Песиле тал, песиле тал –
язның тәүге сәламе.
Нурлы яшьлегемә өсти
яз бүләге, яз яме.

Кушымта:
Песиле тал, мамык алка,
күңелне кузгатасың,
яшь кызларның йөрәгендә
мәхәббәт уятасың.

Песиле тал, песиле тал –
хыялларым җилкәне.
Кайнар мәхәббәт – бүләгем,
өзелеп көтәм иркәмне.

Кушымта:
Песиле тал, мамык алка,
күңелне кузгатасың,
яшь егетләр йөрәгендә
олы дәрт уятасың.

Песиле тал бөдрә-бөдрә,
алкалары кулымда.
Зур бәхетләр алып килсен
безнең тормыш юлында.

Кушымта:
Песиле тал, мамык алка,
күңелләр кузгатасың,
назга сусаган йөрәктә
ташкыннар уятасың.

ЭЧТӘЛЕК

Матурлык тантанасы. *Госман Садә* ........................................ 3

**Мин тормышка гашыйк**

Казаным .......................... 8
Безнең бәхет ...................... 11
Үтенеч ............................. 12
Булса булсын .................... 12
Авылыма мәдхия .............. 13
Мин былбыл булсам иде ..... 14
«Тәрәзә чиертә егет...» ........ 14
«Якын килсәң, ялкын өтә, пешерә...» .................... 14
Мәхәббәткә дару ............... 15
«Ыргы кирәкми йөрәккә...» 15
Кояшка алмашка .............. 15
Мәңге калсын сөю ............ 16
«Ашкынулы йөрәкләргә...» .. 16
Үпкәләмим ....................... 17
Күз .................................. 17
Язым иртә килде ............... 18
Кызларыма ....................... 19
Сөю – бөек ләззәт ............. 20
Сандугачтан җыр кала ........ 20
Мин язларга ышанам .......... 20
Гүзәл кыш ........................ 21
Игенче ............................ 21
«Чәчәкле язга барешә...» .... 22
Табигатьтә камиллек .......... 22
Кояшлы моң ..................... 22
Укытучыма ...................... 23
Язгы таң хатирәсе ............. 24

**Мин дөньяны яхшыртырга телим**

Ватаным дип сөеп әйтү өчен 26
Гомер юлы – сират күпере ... 26
Вакыт ............................. 27
Язмыш ............................ 28
Уфтанмыйк ...................... 28
Юл чатында ..................... 28
«Күбәләкнең сарысы бар, кызылы...» ...................... 30
«Бу дөньяның сигез ягы бар дип...» ......................... 30
«Тылсымлы алтын балыктан...» 30
Хөкемдарлар .................... 30
Төш ................................ 31
Елга зары ........................ 32
Мөһер ............................. 32
Кем мактауга лаек ............ 32
Хакыйкать ....................... 33
Йөрәк хөкемгә хаклымы? .... 33
Уздырмаска иде ................ 33
Үз мәнфәгате .................... 34
«Син кулыңа каләм алсаң...» 34
«Тәмуг салкыннары дибез...» 34
Кеше күңеле ..................... 34
Сөенеч ............................ 35
Фәлсәфә .......................... 35
Күләм ............................. 35
Борынгылар сүзе ............... 35
Бер абынгач... ................... 36
Үзем турында ................... 36
Саксыз гына бер сүз әйттең .. 37
И йөрәк... ........................ 37
Меңенче кәррә .................. 38

**Мин әрним, көенәм, уйланам**

Ник шулай Рәсәйдә? .......... 40
«Нәни генә күлдәвектә...» ... 40
Хаким зары ...................... 41
Дуслык – сынау ................ 42
Татарга бил нәрсәгә? .......... 42
Акыл кергәч ..................... 43

Ник түзәбез? ........................ 44
Терсәк якын, тешләп булмый 44
Татарым ........................... 45
Без кем? ........................... 46
Сының булса... .................. 46
Зилзилә төсле ................... 47
Аңга килү ........................ 47
Кычыткан кыйссасы ......... 48
«Кимсетү ярамый күлне...» .. 49
Заман гаепләме? ................ 50
Уйга талсам... .................. 51
Карт имән ....................... 52
Дөнья безне ат иткән ич ..... 53
Бер йөрәк бит... ............... 54
Җан көзгесе ...................... 54
Төнге хыял ....................... 55
Сагыну ............................ 55
Тагын үзем турында .......... 56
Изге теләк ....................... 57
«Пычрак изеп...» .............. 57
Синнән сорыйм, Ходай ...... 58
«Сукыр лампа диеп кимсетмәгез...» ...................... 59
Мин хаким дә, кол да ......... 59
Гайбәтче ......................... 59
Узгынчы .......................... 60
Таш түгел ........................ 60

### Мин шаярам, көләм

Шүрәленең Казанда күргәннәре ........................... 62
Тәкъва эшмәкәргә ............. 67
Килде-килде халыкка «влач» 67
Эрзац .............................. 67
Офык .............................. 68
Капка .............................. 68
Ник шулай... .................... 68
Кодалардан бик уңдым ....... 69
Симез үрдәк ..................... 70
Тәүбә ............................... 70
«Йолдыз»га ярдәм кирәк .... 71
Маркет ачтым .................... 72
«Кая китте яшьлек елларым дип...» ........................ 73
Качам әле ........................ 73
Җитмеш яшьлекләр манифесты ......................... 73
Ашыкма әле, картлык ........ 74
«Җырлаганда биим диеп...» 74
Йозак белән Ачкыч ........... 74
Картайдым дип уйлама ....... 75
Кыш оялсын дип... ........... 75
Безнең тормыш – зур театр .. 76

### Җырлыйк әле бергәләп

Биек тә генәй тауның, һәй, түбәсе. *Л.Батыр-Болгари* көе .... 78
Горур бөркет. *Л.Батыр-Болгари* көе ....................... 82
Мәңгелек юлы. *С.Ибраһимов* көе ............................. 87
Сөембикә манарасы. *Л.Батыр-Болгари* көе ........... 89
Сабыр ит, сандугач, сайрама. *Л.Батыр-Болгари* көе ..... 95
Сөеләсем бардыр йә сөясем... *М.Имашев* көе ............... 101
Балачак. *Ф.Хатипов* көе ..... 102
Ялгышасы килә йөрәкнең. *Ф.Галәмиев* көе .............. 104
Гөлсинә. *Ф.Галәмиев* көе ..... 105
Синнән соң. *Ф.Хатипов* көе 106
Песиле тал. *Ф.Хатипов* көе 108

Литературно-художественное издание

*Хасанов Анас Хасанович*

**ВОЙДИТЕ В ДУШУ МОЮ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

*Хәсәнов Әнәс Хәсән улы*

**УЗЫГЫЗ КҮҢЕЛ ТҮРЕМӘ**

Мөхәррире *Л.Ә.Гыйззәтуллина*
Рәссамы *А.А.Тимергалина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Музыкаль мөхәррире һәм ноталарны компьютерда җыючысы
*Г.Х.Беляева*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Л.Р.Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 13.10.2010.
Форматы 84´108 1/32. Шартлы басма табагы 5,88.
Тиражы 2000 д. Заказ О-1473.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.